
**Балтач муниципаль районы Балтач урта гомуми белем мәктәбенең**

татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Шакирҗанова Резеда Рафаэль кызының
2016-2018 нче еллардагы педагогик эшчәнлегенә бәяләмә

Шакирҗанова Резеда Рафаэль кызы - югары белемле педагог, КДПУны тәмамлап, Чепья урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башлый, 2003 нче елдан хезмәт юлын Балтач урта мәктәбендә дәвам итә. Һөнәре һәм белгечлеге буенча гомуми стажы -17 ел. 2018 нче елдан югары квалификацион категориягә ия.

Шакирҗанова Р.Р. - тирән белемле, методик осталыкка омтылучы, иҗади эшләүче педагог. Укытучы һәр дәрескә яңалык алып килә, укучыларның фикерләү сәләтен үстерә, белемен арттыра, рухи дөньясын баета.

Резеда Рафаэль кызы соңгы 3 елда урта һәм югары сыйныфларда эшләде. Ул укыткан сыйныфларда белем сыйфаты динамикасы күзәтелә.




**2015-2016 ук. елы** өлгереш- 100%, сыйфат-татар теле 77%, тат. әдәб 93%

**2016-2017 ук. елы** өлгереш -100%, качество- татар теле 80%, тат. әдәб 93%

**2017-2018 ук. елы** өлгереш -100%, качество- татар теле 84%, тат. әдәб 93%

Укучыларда туган ягың белән горурлану, ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләү, туган төбәкнең тарихын өйрәнүдә кызыксыну булдыру, күренекле шәхесләрне хөрмәт итү, туган телгә, әдәбиятка мәхәббәт уяту – Резеда Шакирҗанова эшенең төп максаты. Әлеге максатны тормышка ашыруда, әлбәттә, укытучы төрле традицион булмаган дәрес формаларын: әйтик,

сөйләшү һәм башкаларны киң куллана. Бигрәк тә, дәресләрнең нәтиҗәлелегенарттыруда заманча технологияләрне куллану нык ярдәм итә. Резеда Рафаэль кызы үзенең дәресләрендә мультимедиа технологияләреннән оста файдалана. Укучыларның иҗади күзаллауларын үстерүгә, укыту-тәрбиягә милли төбәк компонентын кертүгә дә нык игътибар итә. Шуның нәтиҗәсендә район һәм республика күләмендә урыннар яулаган укучылары - аның горурлыгы.

**Олимпиада нәтиҗәләре:**

| Укучының исеме, классы | Фәне | Нәтиҗәсе(урыны) | Уку елы |
|---|---|---|---|
| Канафеева Алина, 6-б | Татар теле, муниципаль | Җиңүче | 2016 |
| Гайсина Зиля 9-б | Татар әдәбияты, муниципаль | Призер | 2016 |
| Хәбриева Малика, 7-б | Татар теле, муниципаль | Призер | 2017 |
| Хабриева Малика, 7-б | Татар әдәбияты, муниципаль | Җиңүче | 2017 |
| Гайсина Зиля 9-б | татар теле, муниципаль | Җиңүче | 2017 |
| Салахова Эльвира, 9-а | Татар әдәбияты, муниципаль | Призер | 2017 |
| Гайсина Зиля 9-б | Татар теле, республика | Призер | 2018 |
| Маннапова Алиса, 9-б | Татар теле, республика | Призер | 2018 |
| Ибрагимова Гузель, 8-б | Татар теле, муниципаль | Җиңүче | 2018 |
| Канафеева Алина,8-б | Татар теле, муниципаль | Призер | 2018 |
| Хабриева Малика, 8-б | Татар теле, муниципаль | Призер | 2018 |
| Ибрагимова Фазиля, 10-б | Татар теле, муниципаль | Җиңүче | 2018 |
| Гайсина Зиля, 10-б | Татар теле, муниципаль | Призер | 2018 |
| Маннапова Алиса, 10-б | Татар теле, муниципаль | Призер | 2018 |
| Гайсина Зиля, 10-б | Татар әдәбияты, муниципаль | Җиңүче | 2018 |
| Салахова Эльвира, 10-б | Татар әдәбияты, муниципаль | Призер | 2018 |
| Ибрагимова Гузель, 8-б | Татар теле, республика | Призер | 2019 |
| Гайсина Зиля, 10-б | Татар теле, | Призер | 2019 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | республика | | |

**Фәнни-гамәли конференцияләр:**

1. “Фән һәм мәдәният: яңа караш” студентлар һәм укучыларның халыкара фәнни-гамәли конференциясе, Саба, 2016. (III нче дәрәҗәле диплом)

2. И. Газиның 110 еллыгы уңаеннан регионара фәнни укулар, 2016 г. (III нче дәрәҗәле диплом)

3. Туфан Миңнуллин исемендәге IV республика конференциясе, 2016. (III нче дәрәҗәле диплом)

4. КНИТУ тарафыннан үткәрелгән “Вперед в прошлое - 2017” иҗади бәйгесе, “Минем ачышларым” секциясе, 2017, (лауреат)

5.Советлар Союзы Герое С. А. Әхтәмов истәлегенә багышланган «Память сердца» дип исемләнгән укучыларның VI фәнни-гамәли конференциясе, Кукмара, 2017. (1 урын, грамота)

6. Советлар Союзы Герое С. А. Әхтәмов истәлегенә багышланган «Память сердца» дип исемләнгән укучыларның VI фәнни-гамәли конференциясе, Кукмара , 2017. (2 урын, грамота)

7. “Экология родного края: проблемы и пути их решения” дип исемләнгән район конференциясе, Балтач, 2018. (2 урын, грамота)

8. Советлар Союзы Герое С. А. Әхтәмов истәлегенә багышланган «Память сердца» дип исемләнгән укучыларның VII фәнни-гамәли конференциясе, Кукмара, 2019. (2 урын, грамота)

9. Муса Җәлил исемендәге V республика фәнни-гамәли конференциясе, Балтач, 2019, (III нче дәрәҗәле диплом)

**Иҗади бәйгеләр:**

1. “Коррупциягә каршы көрәш” темасына республика күләмендәге иҗади эшләр (иншалар) бәйгесенең муниципаль этабы. Газизуллин Рахман, (IIурын)

2. “Парклар маршы 2016” халыкара акциясе(“Лукоморье” әдәби эшләр конкурсы), бәйгесенең муниципаль этабы. Шигапов Ислам, (IIурын)

3. Россия күләмендә «Илһам» яшь язучылар бәйгесе, зона этабы, Газизуллин Рахман. 2016, дипломант.

4. “Балалар урман турында” иншалар бәйгесе, муниципаль этап, Шиһапов Ислам, 2017. (IIурын)

5. “Без тормышны сайлыйбыз!” республика иншалар бәйгесе, муниципаль этап, Шакирҗанова А. 2017, (1 урын)

6. «Детство без границ» дип исемләнгән халыкара фестиваль, муниципаль этап, Ибраһимова Гүзәл, (1 урын)

7. “Яңа ел әкияте” республика бәйгесенең муниципаль этабы, Ибраһимова Гүзәл, (1 урын)

Шакирҗанова Резеда Рафаэль кызы үз эшендәге уңай тәҗрибәне тарату буенча да эш алып бара. 2016-2018 нче еллар эчендә мәктәп, район,

республика, төбәкара семинарларда ул үткәргән ачык дәресләр югары профессиональ дәрәҗәдә уза. Дәресләрендә, класстан тыш чараларда куллану өчен кирәкле материалларны матур, фәнни, публицистик әдәбияттан, методик ярдәмлекләрдән, интернет ресурсларыннан туплый. Укучыларны кызыксындыру, җанландыру алымнарын урынлы файдаланып, дәресләрен нәтиҗәле, методик яктан дөрес, ФДБС таләпләренә туры китереп үткәрә. Балаларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләрен истә тотып, кечерәк классларда уеннардан, урта һәм өлкән сыйныфларда укучыларны фикерен, курыкмыйча, дөрес әйтә белүгә этәрә торган тәнкыйди фикерләүне үстерү технологиясе, Сингапур структуралары, рус төркемнәрендә коммуникатив технологиянең эш алымнарына өстенлек бирә. Компьютер технологияләрен дә уңышлы куллана.

**2016-2018 нче елларда уздырылган ачык дәресләр:**

1. “Белем-шоу” уены, 8 класс. Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының район семинарында, 2016
2. “Рәвешләр иленә сәяхәт”, 6 класс. Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының зона семинарында, 2017
3. “Матур итеп яшик әле, Гомер тик бер генә килә ул”, (Нәҗип Әминов белән очрашу кичәсе). “Туган тел” айлыгы кысаларында район күләмендә уздырылган дәрестән тыш чара, 2018
4. “Саннарны кабатлау”, 6 класс. Район күләмендә “Ел укытучысы” кысаларында ачык дәрес, 2018

Бу дәресләрдә, дәрестән тыш чараларда катнашкан коллегалары аларны югары бәяләде, педагогик, методик яктан осталыкка ирешкәнлеген, ФДБСның нигезендә яткан системалы-эшчәнлекле якын килү таләбенә җавап бирүен ассызыклады.

Моннан тыш укытучы үз тәҗрибәсен таратуның башка формаларын да актив куллана:

<u>Мастер класслар</u>:

1. “Туган телне укыту серләре”, татар теле һәм әдәбияты укытучыларының белемнәрен күтәрү курслары кысаларында, 2016
2. “25нче сәгатьне ничек табарга?”, район күләмендә “Ел укытучысы” кысаларында үткәрелгән мастер-класс, 2018

<u>Методик семинар</u> “ФДББС шартларында туган телне укытуда нәтиҗәләргә ирешү юллары” темасына чыгыш, татар теле һәм әдәбияты укытучыларының республика семинары, 2016

<u>Коллектив җыентыкларда:</u>

1. И.Г. Сөләйманова “Татар теленнән ДЙА әзерләнү өчен кулланма”да , 7 вариант.
2. Татар теле. Дәүләт (йомгаклау) аттестациясенә әзерләнү өчен кулланма. 9 сыйныф. Рус телендә сөйләшүче укучылар өчен.

<u>Шәхси сайтта :</u> http://rezeda.ucoz.com/

Резеда Рафаэль кызы соңгы елларда “Федераль дәүләт белем бирү стандартларына нигезләнеп, татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә милли үзаңлы шәхес тәрбияләү ” дигән методик тема буенча эшли. Бу юнәлештә эшләү өчен кирәкле материаллары: методик ярдәмлекләр, таратма материаллар, компьютер презентацияләренә бай, төрле, алар Резеда Рафаэлевна җитәкләгән татар теле һәм әдәбияты кабинетында саклана. Кабинеты эстетик, санитар-гигиена таләпләренә җавап бирә, таратма материаллар, методик, матур, фәнни әдәбият даими тулыландырыла. Балтач урта мәктәбендә эшләү дәверендә Резеда Рафаэль кызы үзен тынгысыз, эзләнүчән класс җитәкчесе буларак та күрсәтте. Ул җитәкләгән 8-б сыйныфы укучылары мәктәптә үткәрелгән чараларда актив катнаша һәм 2017-2018 нче уку елы нәтиҗәләре буенча аның сыйныфы 2 урынга лаек булды.

Шакирҗанова Резеда Рафаэль кызының районның татар теле укытучылары арасында абруе зур, шуңа күрә олимпиада эшләрен, бәйгеләргә тәкъдим ителгән сочинениеләрне тикшергәндә эксперт төркемнәрдә даими катнаша. 2016нчы елда “Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының иң яхшы сайты” муниципаль бәйгесендә 2нче урынны яулады.

Шакирҗанова Резеда Рафаэль кызы 2015 нче елда “Безнең яхшы укытучы” грантына, 2019 нчы елда “Ел укытучысы” бәйгесенең муниципаль этабында 2 урынга лаек булды.

Балтач районы башкарма комитетының
мәгариф идарәсе җитәкчесе А. Ю. Зәкиева

“УПРАВЛЕНИЕ ОБРАЗОВАНИЯ БАЛТАСИНСКОГО РАЙОННОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОГРН 1021607758259
ИНН 1612000739